**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Об образовании Координационного совета по патриотическому воспитанию граждан в Республике Татарстан

В соответствии с пунктом 3 части 2 статьи 6, статьей 8 Закона Республики Татарстан от 9 декабря 2023 года № 123-ЗРТ «О патриотическом воспитании граждан в Республике Татарстан», в целях совершенствования взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также иных субъектов патриотического воспитания **постановляю:**

1. Образовать Координационный совет по патриотическому воспитанию граждан в Республике Татарстан.

2. Утвердить Положение о Координационном совете по патриотическому воспитанию граждан в Республике Татарстан (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
05 июля 2024 года
№ 517

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан
от «05» июля 2024 года
№ 517

**Положение**
**о Координационном совете по патриотическому воспитанию граждан в Республике Татарстан**

I. Общие положения

1. Координационный совет по патриотическому воспитанию граждан в Республике Татарстан (далее – Координационный совет) является консультативно-совещательным органом, образованным в целях совершенствования взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), а также иных субъектов патриотического воспитания.

2. Координационный совет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

II. Основные задачи Координационного совета

3. Основными задачами Координационного совета являются:

а) рассмотрение вопросов реализации государственной политики в сфере патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан и межведомственного взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также иных субъектов патриотического воспитания;

б) подготовка предложений Раису Республики Татарстан по актуальным вопросам патриотического воспитания граждан, совершенствованию реализации государственной политики в сфере патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан;

в) обеспечение взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также иных субъектов патриотического воспитания

по вопросам реализации государственной политики в сфере патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан;

г) выработка и рассмотрение рекомендаций по вопросам реализации государственных программ, принимаемых в Республике Татарстан, в части, касающейся вопросов патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан;

д) выработка и рассмотрение рекомендаций по вопросам совместной деятельности органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также иных субъектов патриотического воспитания по реализации значимых проектов в сфере патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан;

е) ежегодное представление Раису Республики Татарстан отчета о реализации государственной политики в сфере патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан.

4. Координационный совет для решения возложенных на него задач имеет право:

а) запрашивать и получать в соответствии с законодательством от органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также иных субъектов патриотического воспитания информацию и материалы по вопросам, относящимся к компетенции Координационного совета;

б) приглашать в установленном порядке на свои заседания представителей органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также иных субъектов патриотического воспитания;

в) инициировать проведение научных исследований, социологических опросов по актуальным вопросам реализации государственной политики в сфере патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан;

г) привлекать в установленном порядке к работе Координационного совета специалистов;

д) создавать постоянные и (или) временные комиссии (рабочие группы) для согласованного решения задач в области патриотического воспитания граждан в Республике Татарстан.

## III. Состав Координационного совета

5. Состав Координационного совета утверждается Раисом Республики Татарстан.

6. В состав Координационного совета входят председатель, заместители председателя, секретарь и иные члены Координационного совета, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

В состав Координационного совета включаются депутаты Государственного Совета Республики Татарстан, представители органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов, органов местного самоуправления, социально ориентированных

некоммерческих организаций, осуществляющих деятельность в сфере патриотического, в том числе военно-патриотического, воспитания граждан. В состав Координационного совета при необходимости могут включаться представители иных субъектов патриотического воспитания.

7. Председатель Координационного совета:

а) руководит работой Координационного совета, определяет перечень, сроки и порядок рассмотрения вопросов на заседаниях Координационного совета;

б) распределяет полномочия (обязанности) между заместителями и членами Координационного совета;

в) определяет и утверждает повестку дня, дату, время и место проведения заседаний;

г) назначает на время своего отсутствия одного из заместителей исполняющим обязанности председателя Координационного совета;

д) утверждает протоколы заседаний, подписывает другие документы Координационного совета.

8. Секретарь Координационного совета:

а) принимает участие в заседаниях Координационного совета;

б) уведомляет членов Координационного совета о месте, дате, времени проведения заседания не менее чем за три рабочих дня до дня проведения заседания, рассылает повестку дня заседания;

в) отвечает за подготовку протоколов заседаний и других документов Координационного совета.

9. Члены Координационного совета:

а) участвуют лично в заседаниях Координационного совета;

б) выносят на обсуждение предложения по вопросам, находящимся в компетенции Координационного совета;

в) осуществляют иные мероприятия по подготовке, исполнению решений Координационного совета.

## IV. Заседания и решения Координационного совета

10. Свою работу Координационный совет строит на основании ежегодного плана мероприятий. План мероприятий формируется коллегиально в соответствии с предложениями членов Координационного совета и утверждается Координационным советом.

11. Заседания Координационного совета проводятся в очной форме или в форме заочного голосования по мере необходимости, но не реже одного раза в шесть месяцев.

12. Заседания Координационного совета ведет председатель или по его поручению один из заместителей председателя.

13. Заседание Координационного совета считается правомочным, если в нем принимают участие не менее двух третей от общего числа членов Координационного совета. Решение Координационного совета считается принятым, если за него проголосовало не менее половины членов,

присутствующих на заседании. При равенстве голосов голос председательствующего является решающим.

По решению председателя Координационного совета решения могут приниматься путем проведения письменного опроса членов Координационного совета (заочное голосование).

14. Решения Координационного совета оформляются протоколом. Протокол подписывается секретарем Координационного совета и утверждается председательствующим. Протоколы по итогам заседания Координационного совета оформляются в течение 10 рабочих дней со дня проведения заседания Координационного совета и в трехдневный срок после подписания председательствующим рассылаются всем членам Координационного совета, заинтересованным органам исполнительной власти Республики Татарстан, иным государственным органам, органам местного самоуправления, а также иным субъектам патриотического воспитания.

## V. Обеспечение деятельности Координационного совета

15. Организационно-техническое, документационное, информационное и иное обеспечение деятельности Координационного совета осуществляется Министерством по делам молодежи Республики Татарстан.

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «05» июля 2024 года

№ 517

**Состав**
**Координационного совета по патриотическому воспитанию граждан в Республике Татарстан**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, председатель Координационного совета |
| Фазлеева Лейла Ринатовна | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, заместитель председателя Координационного совета |
| Мухарлямов Руслан Робертович | заместитель Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан – руководитель Департамента Раиса Республики Татарстан по вопросам внутренней политики, заместитель председателя Координационного совета |
| Садыков Ринат Наильевич | министр по делам молодежи Республики Татарстан, секретарь Координационного совета |
| Аюпова Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |
| Бородин Александр Ильич | председатель Республиканской общественной организации ветеранов (инвалидов) «Союз ветеранов Республики Татарстан» Общероссийской общественной организации ветеранов «Российский союз ветеранов», ветеран Вооруженных Сил Российской Федерации (по согласованию) |
| Валеева Зиля Рахимьяновна | председатель Общественной палаты Республики Татарстан (по согласованию) |
| Волынец Ирина Владимировна | Уполномоченный по правам ребенка в Республике Татарстан (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Губайдуллин Экзам Саматович | председатель Ассоциации «Совет муниципальных образований Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Демидов Виктор Николаевич | главный федеральный инспектор по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Денькин Алексей Юрьевич | заместитель военного комиссара Республики Татарстан (по согласованию) |
| Егоров Иван Михайлович | генеральный директор акционерного общества «Холдинговая компания «Ак Барс», председатель Координационного совета Республики Татарстан по вопросам ветеранов боевых действий в Республике Афганистан, участников вооруженных конфликтов и контртеррористических операций на территории Северо-Кавказского региона (по согласованию) |
| Залялова Анфиса Григорьевна | директор государственного автономного профессионального образовательного учреждения «Казанский педагогический колледж», председатель некоммерческого партнерства «Совет директоров образовательных учреждений среднего профессионального образования Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Зарипов Айрат Ринатович | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по образованию, культуре, науке и национальным вопросам (по согласованию) |
| Зарипов Раушан Булатович | начальник Управления по вопросам здравоохранения, спорта и формирования здорового образа жизни Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Зарипова Эльмира Амировна | министр труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан |
| Захарова Светлана Михайловна | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по социальной политике (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Камалетдинов<br>Тимур Ренатович | директор государственного бюджетного учреждения «Республиканский центр молодежных формирований по охране общественного порядка «Форпост» |
| Коноплев<br>Александр Юрьевич | председатель Совета Региональной общественной молодежной организации «Объединение «Отечество» Республики Татарстан (по согласованию) |
| Леонов<br>Владимир Александрович | министр спорта Республики Татарстан |
| Литвинов<br>Дмитрий Константинович | директор государственного автономного учреждения Республики Татарстан «Республиканский центр спортивно-патриотической и допризывной подготовки молодежи «Патриот» |
| Миннуллин<br>Марсель Мансурович | министр здравоохранения Республики Татарстан |
| Миронченко<br>Валерий Николаевич | начальник федерального государственного казенного общеобразовательного учреждения «Казанское суворовское военное училище Министерства обороны Российской Федерации» (по согласованию) |
| Мубаракшин<br>Айрат Ильдусович | руководитель управления по работе с волонтерами автономной некоммерческой организации «Дирекция спортивных и социальных проектов», исполнительный директор автономной некоммерческой организации «Информационно-ресурсный центр добровольчества Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Салимгараев<br>Айдар Саитгараевич | руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |
| Сафин<br>Ленар Ринатович | ректор федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Старостин Сергей Петрович | председатель правления Регионального общественно-государственного объединения «Добровольное общество содействия армии, авиации и флоту (ДОСААФ) Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Сулейманов Тимур Джавдетович | председатель Совета регионального отделения Общероссийского общественно-государственного движения детей и молодежи «Движение первых» Республики Татарстан (по согласованию) |
| Урин Александр Николаевич | временно исполняющий обязанности начальника федерального государственного казенного военного образовательного учреждения высшего образования «Казанское высшее танковое командное ордена Жукова Краснознаменное училище» Министерства обороны Российской Федерации (по согласованию) |
| Фазылов Ринат Рафаэлевич | руководитель Исполнительного комитета Регионального отделения Общероссийского общественного движения «НАРОДНЫЙ ФРОНТ «ЗА РОССИЮ» в Республике Татарстан, координатор республиканского движения «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» (по согласованию) |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы төзү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 2023 елның 9 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы 2 кисәге 3 пункты, 8 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, шулай ук патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектларның үзара эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы төзергә.

2. Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 05 июль
№ 517

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «05» июлендәге
517 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы (алга таба – Координация советы) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары), шулай ук патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектларның үзара эшчәнлеген камилләштерү максатларында төзелгән консультатив-киңәшмә орган булып тора.

2. Координация советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Координация советының төп бурычлары

3. Координация советының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, шулай ук патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектларның ведомствоара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен карап тикшерү;

б) Татарстан Республикасы Рәисенә гражданнарга патриотик тәрбия бирүнең актуаль мәсьәләләре, Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

в) Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, башка дәүләт

органнарының, җирле үзидарә органнарының, шулай ук патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектларның үзара эшчәнлек алып баруын тәэмин итү;

г) Татарстан Республикасында кабул ителә торган дәүләт программаларын, Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү мәсьәләләренә кагылышлы өлештә дә, гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү һәм аларны карап тикшерү;

д) Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә мөһим проектларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, шулай ук патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектларның уртак эшчәнлек алып бару мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү һәм аларны карап тикшерү;

е) ел саен Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында хисап бирү.

4. Координация советы үз алдында торган бурычларны хәл итү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектлардан законнар нигезендә Координация советы компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

б) билгеләнгән тәртиптә үз утырышларына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектлар вәкилләрен чакырырга;

в) Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның актуаль мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренүләр, социологик сораштырулар уздыру башлангычы белән чыгарга;

г) билгеләнгән тәртиптә Координация советы эшенә белгечләрне җәлеп итәргә;

д) Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә бурычларны үзара килештереп хәл итү өчен даими һәм (яисә) вакытлы комиссияләр (эш төркемнәре) төзергә.

## III. Координация советы составы

5. Координация советы составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан расланa.

6. Координация советы составына рәис, рәис урынбасарлары, секретарь һәм Координация советының башка әгъзалары керә, алар аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша.

Координация советы составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, гражданнарга патриотик, шул исәптән хәрби-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре кертелә. Координация советы составына, кирәк булганда, патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектлар вәкилләре кертелә ала.

7. Координация советы рәисе:

а) Координация советы эшенә җитәкчелек итә, Координация советы утырышларында карала торган мәсьәләләр исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгели;

б) урынбасарлары һәм Координация советы әгъзалары арасында вәкаләтләрне (вазыйфаларны) бүлә;

в) утырышларның көн тәртибен, уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

г) үзе эш урынында булмаган вакытта урынбасарларыннан берсен Координация советы рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп билгели;

д) Координация советы утырышлары беркетмәләрен раслый һәм башка документларга кул куя.

8. Координация советы секретаре:

а) Координация советы утырышларында катнаша;

б) Координация советы әгъзаларына утырышны уздыру көненә кадәр кимендә өч эш көне кала утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен җибәрә;

в) Координация советы утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

9. Координация советы әгъзалары:

а) Координация советы утырышларында шәхсән катнаша;

б) Координация советы компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча фикер алышуга тәкъдимнәр бирә;

в) Координация советы карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

## IV. Координация советы утырышлары һәм карарлары

10. Координация советы үз эшен еллык чаралар планы нигезендә төзи. Чаралар планы Координация советы әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә коллегиаль рәвештә формалаштырыла һәм Координация советы тарафыннан раслана.

11. Координация советы утырышлары турыдан-туры катнашу яисә читтән торып тавыш бирү рәвешендә кирәк булган саен, әмма кимендә алты айга бер тапкыр үткәрелә.

12. Координация советы утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

13. Координация советы утырышы, әгәр анда Координация советы әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, эш алып барырга хокуклы дип санала. Координация советы карары, әгәр аның өчен утырышта катнашкан әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Координация советы рәисе карары буенча карарлар Координация советы әгъзалары арасында язмача сораштыру уздыру (читтән торып тавыш бирү) юлы белән кабул ителергә мөмкин.

14. Координация советы карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәгә Координация советы секретаре кул куя һәм рәислек итүче тарафыннан раслана. Координация советы утырышы йомгаклары буенча беркетмәләр Координация советы утырышы уздырылган көннән 10 эш көне дәвамында рәсмиләштерелә һәм рәислек итүче тарафыннан кул куелган көннән өч көн эчендә Координация советының барлык әгъзаларына, кызыксынган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, шулай ук патриотик тәрбия бирү буенча башка субъектларга җибәрелә.

## V. Координация советы эшчәнлеген тәэмин итү

15. Координация советы эшчәнлеген оештыру-техник яктан, документлар, мәгълүмат белән һәм башкача тәэмин итүне Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы башкара.

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «05» июлендәге
517 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы составы**

| | |
|---|---|
| Песошин<br>Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Координация советы рәисе |
| Фазлыева<br>Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Координация советы рәисе урынбасары |
| Мөхәрләмов<br>Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе, Координация советы рәисе урынбасары |
| Садыйков<br>Ринат Наил улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, Координация советы секретаре |
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бородин<br>Александр Ильич | «Россия ветераннар берлеге» Бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы рәисе, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре ветераны (килешү буенча) |
| Вәлиева<br>Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Волынец<br>Ирина Владимировна | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гобәйдуллин<br>Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Демидов<br>Виктор Николаевич | Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор (килешү буенча) |
| Денькин<br>Алексей Юрьевич | Татарстан Республикасы хәрби комиссары урынбасары (килешү буенча) |
| Егоров<br>Иван Михайлович | «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры, Әфганстан Республикасында хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм Төньяк-Кавказ төбәге территориясендә кораллы конфликтлар һәм террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашучылар мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы координация советы рәисе (килешү буенча) |
| Җәләлова<br>Анфиса Григорьевна | «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры, «Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре директорлар советы» коммерциячел булмаган партнерлыгы рәисе (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Раушан Булат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Зарипова<br>Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Захарова<br>Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Камалетдинов<br>Тимур Ренат улы | «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Коноплев<br>Александр Юрьевич | Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк иҗтимагый яшьләр оешмасы советы рәисе (килешү буенча) |
| Леонов<br>Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Литвинов<br>Дмитрий Константинович | Татарстан Республикасының «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге республика үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры |
| Миңнуллин<br>Марсель Мансур улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Миронченко<br>Валерий Николаевич | «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесе башлыгы (килешү буенча) |
| Мөбарәкшин<br>Айрат Илдус улы | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасының волонтерлар белән эшләү идарәсе җитәкчесе, «Татарстан Республикасы ирекләләр хәрәкәтенең мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Старостин<br>Сергей Петрович | «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсе идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Сөләйманов<br>Тимур Җәүдәт улы | Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» бөтенроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе советы рәисе (килешү буенча) |
| Урин<br>Александр Николаевич | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казан Кызыл байраклы Жуков орденлы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Фазылов<br>Ринат Рафаэль улы | Татарстан Республикасында «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәте төбәк бүлекчәсе Башкарма комитеты җитәкчесе, «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» республика хәрәкәте координаторы (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |